# Мәктәп хәбәрчесе

**№4** (№35) апрель 2022 ел

Түбән Майна урта мәктәбе газите

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru

*/Мөхәррир сүзе/*


ГОД ЦИФРОВИЗАЦИИ В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНДА ЦИФРЛАШТЫРУ ЕЛЫ

## *2022 ел-Татарстанда цифрлаштыру елы*

Дөнья тиз үзгәрә, масштаблы цифрлы трансформация һәр кешегә, һәр һөнәргә, һәр өлкәнең барлык тармакларына кагыла. Бу, беренче чиратта, безнең тормыш сыйфатын арттыру, тормыш-көнкүрешебезне тәэмин итү һәм башка бик күп мөмкинлекләрне ача. Әлбәттә, һәр нәрсәнең чиге булырга тиеш. Әгәр телəсә кайсы даруны күбрәк кулланса, ул агуга әйләнергә мөмкин. Санлаштыру белән дә шул ук хәл. Безгә гаҗәеп мөмкинлекләр биргән цифрлаштыруны файдалы итеп куллана белергә кирәк.

Заманча технологияләрне бөтенләй файдаланмау урынсыз булыр иде. Бүген укучыларга клипплы күзаллау хас. Аларга кыска һәм тиз алына торган мәгълүмат кирәк. Дәресләрдә укучылар Лев Толстойның тавышын тыңлый, Тукайга кагылышлы видеоязмалары карый ала, теләсә кайсы интерактив музейда була ала. Төрле предметлардан теләсә кайсы теманы видео аша да аңлау, нечкәлекләренә төшенү мөмкинлеге күп. Имтиханнар өчен биремнәр, аларны аңлаткан язмаларны да карап ала алабыз. Әйткәнемчә, интернет челтәре чиксез мөмкинлекләр бирә. Башка мәктәпләрдәге кебек ноутбук, интерактив такталар кабинет саен куелган. Замана таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә диясем килә уку кабинетларын.

Кайбер укытучылар әйтүенчә, укучыларны яңа технологияләрсез дә кызыксындырып була. Дәресне уен рәвешендә оештырып, теләсә кайсы укучыны җәлеп итәргә мөмкин. Укучылар бер-берләренең күзенә карап аралаша, дәрес материалларын тотып карап аңлаша да начар түгел. Чөнки мондый белем башта озак саклана, хәтерне яхшырта. Ә тиз алынган кыска мәгълүматны тиз онытыла да диләр кайберәүләр. Виртуаль чынбарлык технологияләре бер эш урынына бәйле булмаган цифрлы тренажерлар куллану мөмкинлеген тудыра, бу өйрәнелә торган технологияләр даирәсен киңәйтә. Мобиль укыту технологияләре теләсә кайсы вакытта һәм теләсә кайсы урында укырга мөмкинлек бирә.




Цифрлаштыру мөмкинлекләрен файдаланып, читтән торып укуны без дә кулландык. Тик нинди генә яхшы булмасын, укучыда теләк булмаса, мондый мөмкинлекнең нәтиҗәсе юк белән бер дәрәҗәдә.

**Нинди генә фикерләр туса да, цифрлаштыру – заман таләбе.** Дәресләрне шундый ысулларга нигезләнеп алып барабыз, Интернетта да укуга бәйле 30 га якын платформа бар. Алар арасында БДИга әзерләнү өчен кирәклеләре дә шактый. Хәтта барлык дәреслекләрнең дә электрон вариантлары бар. 2015 елдан аларга таләп тә кертелде. Укытучы мондый мөмкинлекләрне ничек итеп дөрес файдаланырга, кайсы платформа яки дәреслек уңай нәтиҗә бирәчәгенә юнәлтә дә белергә тиеш була. Мәгарифне цифрлаштыру аны тамырдан, сыйфатлы итеп үзгәртеп корырга кирәк. Педагог яңа технологик инструментлар һәм чиксез диярлек мәгълүмати ресурслар кулланырга өйрәнергә бурычлы.

Цифрлы белем бирүнең төп элементларының берсе – цифрлы грамоталылык. Цифрлы белем – белем бирүнең төп приоритеты, ул контентны цифрлы технологияләр ярдәмендә проектлау һәм куллану сәләте, программалаштыру, график техникалары, визуализация, компьютер графикасы, мультимедиа-курслар эшләү һ.б., мәгълүмат эзләү һәм алмашу, башка укучылар белән аралашу.

Тормышыбызда да интернет мөмкинлекләрен санап бетерү дә мөмкин түгел. Коммуналь хезмәтләргә түләү, товар алу, ерак туганың белән күреп сөйләшү – болар барысы да көндәлек, гадәти эшләр. Шулай да балаларыбызны аралашудан, җанлы очрашудан, бергә уйнау, фикерләшүдән аермасак иде. Алар болай да виртуаль дөньяда яши. Аларга реаль тормышны, чынбарлыкны җиткерәсе килә. Телефон тотып, шунда "яшәп" ана телләрен дә оныталар кебек. Чөнки һәр укытучы диярлек укучының гади аралашуда булган татар сүзен аңламавына борчыла. Ә бу, үз чиратында, телебез өчен генә түгел, милләтебез өчен дә аянычлы. Аралашуны берни белән дә алмаштырып булмаунын бер генә исбатлавы бу.

***Фәнүзә Гафиятуллина, туган тел һәм әдәбият укытучысы***

*/Юл иминлеге/*

## *"Куркынычсыз тәгәрмәч"*



Юл иминлеге буенча республика күләмендәге "Куркынычсыз тәгәрмәч" конкурсы инде беренчә ел рәттән уздырыла. Безнең мәктәпнең ЮИД командасы да бу ярышта ел саен уңышлы чыгыш ясап, алдынгы урыннарны алып килә. Быелгы чараның тәртипләре узган еллардагы кебек иде. Иң беренче иҗади биремнәрне үтәү, юл йөрү кагыйдәләре сорауларына җавап бирү; икенче этапта велосипедта фигуралы йөрү, каршылыкларны узу, велосипед төзелешен һәм һәрберебезгә кирәкле булган беренче медицина ярдәме күрсәтә белү иде. Быелгы команда составында **Гафиятуллин Фаил**, **Залиева Вәсилә**, **Закирова Ләйсән**, һәм **Донсков Артур** чыгыш ясадылар. Укучыларыбыз сынауларда актив һәм уңышлы катнашканнары өчен район күләмендә **III урынга** лаек булдылар. ЮИД командасын юл иминлеге буенча үткәрелгән һәр чарага нәтиҗәле әзерләгәне өчен **Гафиятуллина Руфия апа "Иң яхшы җитәкче"** номинациясендә **III урынга** ия булды.

Апрель аенда мәктәптә, юл йөрү куркынычсызлыгын тәэмин итү максатыннан, **"Өйдән мәктәпкә юл ясыйм"** дип исемләнгән темага рәсем ясау оештырылды. Укучылар үзләренең "өй-мәктәп", "мәктәп-өй" маршруты күрсәтелгән план-рәсем ясадылар. Хәзер башлангыч сыйныф укучыларының һәрберсенең дә шундый маршруты бар.

***Зөлфирә Сафиуллина, Х сыйныф укучысы***

*/Безнең спорт/*



## *Шашка-шахмат турниры*

Безнең мәктәптә шашка, шахмат уеннары белән кызыксынучылар шактый. Бу спорт төрләре өчен барлык мөмкинлекләр дә тудырылган. Киңәш алырга осталары, уйнар өчен шартлар бар. Апрель аенда мәктәп күләмендә шашка-шахмат турниры оештырылды. Җитәкчесе итеп Туктамышев Рифкать абый, ярдәмче-оештыручы итеп Рузилә апа билгеләнде. Судья итеп мәктәпнең шахмат остасы V нче сыйныф укучысы **Гафиятуллин Фаил** сайланды.

Шашка уены буенча **I** урында – **Нурматов Муса, II** урында – **Хәйруллин Айназ, III** урында – **Хусенов Станислав** калды. Шахмат турнирында башлангыч сыйныфлар арасында **I** урынны – **Закирова Ләйсән, II** урынны – **Хусенов Дима, III** урынны – **Камалов Илнур** алдылар. Өлкән һәм урта сыйныфлар арасында шахмат буенча **I** урында – **Хәйруллин Айназ, II** урында – **Залиев Салават, III** урында – **Хусенов Станислав** калды.

Мәктәптә мондый уеннар ешрак кабатланса тагын да әйбәт булыр иде. Ахыр чиктә, барысы да үзебезнең оешканлыктан гына тора.

***Айназ Хәйруллин, VII сыйныф укучысы***

## *Фаил – республика турнирында*

15-18 апрель көннәрендә Актаныш районында авыл җирлеге шахматчылары арасында рапид һәм блиц төрләре буенча Н.И.Мөхәммәтҗанов истәлегенә багышланган XII шәхси-командалы шахмат турниры узды. Турнирда республиканың төрле районнарыннан көчле шахматистлар катнашты. Алар арасында безнең мәктәп укучысы **Гафиятуллин Фаил** дә көч сынашты. Турнир бик киеренке шартларда үтте. Нәтиҗәләр буенча Фаил 2005-2010 елгы укучылар арасында рапид буенча – **III**, блиц буенча – **I** урыннарны яулады. Фаилне уңышлары белән котлап, киләчәктә дә яңа үрләр яулавын телибез.

***Фәнил Зарипов, V сыйныф җитәкчесе***



## *Норлат бәйгесе нәтиҗәләре*

30 апрель көнне Норлат шәһәрендә тренер-укытучылар Ф.Т.Мөхәммәтов һәм З.З.Яруллин истәлегенә уздырылган көрәш буенча ачык ярышларда безнең укучылар катнашты. 60 кг нан югары булган авырлыкта укучыбыз Камалов Илдус I урынны, 25 кг авырлыкта Җамалетдинов Зөлфәт III урынны яулады. Көрәшчеләребезне чираттагы җиңүе белән чын күңелдән котлыйбыз.

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева
Сара Насыйрова
Виктория Нукина
Рузилә Мөхәммәтова
Зөлфирә Сафиуллина

## Уку тизлеге тикшерелде

**/Мәктәп тормышы/**

Апрель аенда башлангыч сыйныф укучылары арасында уку сыйфатын арттыру, әдәби китаплар укырга кызыктыру максатыннан уку тизлеге буенча ярыш уткәрелде. Балалар арасыннан хатасыз, сәнгатьле, иң тиз һәм күп сүз укучыларны барладык. Ярыш нәтиҗәләре буенча I сыйныфтан **Закиров Инсаф, Сафиуллина Гөлсем** һәм **Камалов Илнур**, II сыйныфтан **Хусенов Дима**, III сыйныфтан **Донсков Артур**, IV сыйныфтан **Закирова Ләйсән** җиңүче исеменә лаек булдылар.

## Язгы уеннар

Технология дәресләрендә һәм "Оста куллар" түгәрәгендә укучылар үз куллары белән төрле мавыктыргыч эшләнмәләр ясау белән мәшгуль булалар. Язгы ташуга башлангыч һәм V сыйныф укучылары агачтан көймәләр ясап әзерләнделәр. Алар ул көймәләрен язгы гөрләвекләрдә агыздылар. Бүгенге көндә табигатьтә уйнау балалар өчен сирәк күренеш булса да, алар бу уеннан бик канәгать калдылар.

## Тукай иҗатын онытмыйбыз

Апрель – безгә Тукайны биргән ай. Шул уңайдан бу айда башлангыч сыйныфларда Тукайга багышланган чаралар үткәрелде. Шагыйрьнең тормыш юлына, иҗатына багышланган викторина аеруча мавыктыргыч үтте. Укучылар Тукайның бала чагы, үсмерлек чорына карата бирелгән сорауларга җавап бирделәр. Су аналы, Шүрәлеле Кырлай авылының һәни Габдулла күңелендә калган иң кадерле истәлекләрен барладылар.

## Пушкин картасы буенча чираттагы чара



Пушкин картасының мәдәният хәзинәләре белән танышуда күп мөмкинлекләр бирүен инде беләбез. Бу айда да билетлар алганнан соң, район мәдәният йорты хезмәткәрләре, өлкән сыйныфлар өчен квест оештырдылар. Сораулар барысы да диярлек туган як тарихына, туган телләргә карата бирелде. Без Аксубай төбәге тарихына кагылышлы сорауларга бик теләп җавап бирдек. Командалар арасында ярыш кызык, җанлы барды. 4 команда арасында бәйге кызыклы фактлар белән аралаштырылды. Ахырдан билет алучылар арасында лоторея уйнатылды. X сыйныф укучысы Нукина Вика сумка отты. Шундый күңелле мәдәни чаралар киләчәктә дә булып торсын иде.

## Мәктәп өмәсе

Апрель ае ахырында мәктәп тирәсен җыештыру, яшелчәләрне утырту буенча өмә үткәрелде. Барлык сыйныфлар да актив катнашып, тирә-якның чисталыгын саклауда үзләреннән өлеш керттеләр.

***Рубриканы Рузилә Мөхәммәтова әзерләде, XI сыйныф укучысы***



## Мәктәпкә – яңа ноутбуклар

**/Безнең уңышлар/**

Хәзерге заман укытучысын мәгълүмати технологияләрдән, интернеттан, компьютерлардан башка күз алдына да китерү мөмкин түгел. Инде күптәннән ноутбук белән видеопроекторлар укытучының аерылгысыз атрибуты булып тора. Ләкин нинди генә заманча булмасын, компьютерлар да искерә һәм туза. Укытучыларга 2011 нче елда тапшырылган ноутбукларның күбесе инде сафтан чыкты. Алардан соң 2015 нче елда кайтарылган тар экранлы нетбуклар да, эшләр өчен уңайсызлыгы өстенә, сыйфат ягыннан да бик мактарлык булмадылар. Шул сәбәпле, укытучыларны яңа сыйфатлы ноутбуклар белән тәэмин итү мәктәп алдында торган зур проблемага әверелгән иде.

Ниһаять, Рамазан аенда күктән төшкән бәхет шикелле, барлык укытучыларны да яңа ноутбуклар белән тәэмин итү мөмкин булды. Ел башында, райондагы Ак Барс Банк җитәкчелеге үзләре аркылы хезмәт хаклары күчерелә торган оешмаларга ноутбук бүләк ителәчәге турында белдерделәр. Без дә, мәктәп хезмәткәрләренең хезмәт хакларын моннан 5-6 еллар элек үк Ак Барс Банкта ачылган счетларга күчерүне оештырганлыктан, әлеге бүләккә өмет иттек. Фәрештәләрнең "Амин" дигәненә туры килгәнме, Ак Барс Банк без өметләнгән 1 ноутбук урынына берьюлы 16ны тапшырды. Районда бездәгедән дә күбрәк бүләк бары тик район үзәгендәге зур мәктәпләргә генә бирелде. Ноутбукларны тапшырганда Ак Барс Банкның Аксубай офисы җитәкчесе озак еллар хезмәттәшлек иткәнебез өчен аерым безнең мәктәпкә зур рәхмәт белдерде.

Цифрлаштыру елы уңаеннан шундый зур бүләк ясаганы өчен Республикабызның иң төп финанс оешмасы булган **Ак Барс Банк җитәкчелегенә олы рәхмәтебезне җиткерәбез**. Заманча техника белән коралланган укытучыларның укыту-тәрбия эшчәнлеге тагын да нәтиҗәлерәк булыр дигән өметтә калабыз.

***Рафик Насыйров, мәктәп директоры***

## "Минем шәҗәрәм" конкурсында

**/ Иҗади бәйгеләр/**



Татар мәдәнияте үзәге Казан шәһәре мәгариф идарәсе, Әлки районы "Якташлык" җәмгыяте белән берлектә **"Шәҗәрәм"** дигән Республика конкурсы берничә ел рәттән уздырылып килә. Нәсел тамырларын барлау безнең мәктәп укучылары өчен инде яңалык түгел. Тарих укытучыбыз Рафик абый безгә мондый хәзинәне һәр гаиләгә диярлек табып бирде. Шулай да, республикакүләм уздырылган конкурстан читтә калмаска булдым һәм үзебезнең нәсел шәҗәремне тәкъдим иттем.

Конкурсны Россия кооперация университеты ректоры, Татарстан Дәүләт Советының "Мәрхәмәт-Милосердие" хатын-кыз депутатлары оешмасы рәисе Алсу Нәбиева ачып җибәрде. Ул чыгышында татар халкында җиде буын бабаңны белүнең әһәмиятенә тукталды. Шәҗәрә төзү – нәсел агачы һәм буыннар тезмәсен барлау белән генә чикләнми. Чөнки, нәсел һәм гаилә тарихы – ул илнең дә тарихы. Ул һәр кешенең эшенә һәм тормыш юлына, күпсанлы кардәш-ыруның бәйләнешләренә ачыклык кертә. Гаилә тарихы аша без кемлегебезне, бу якты дөньяга нинди эшләр башкарырга килгәнлегебезне, туган нигезебезнең үткәнен, халкыбызның тарихын ачыклый алабыз. Нәсел тарихларын өйрәнүдә мәшһүр галимнәребез Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхреддин эшен хәзерге заманда да дәвам итүчеләр күп икән. Татар шәҗәрәләрен фәнни яктан дөньякүләм дәрәҗәгә күтәрүче шәхесләр барлыгын күреп, меңьеллык татар тарихында үзебезнең нәселнең дә лаеклы урын биләвенә ышанып кайттым мин бу конкурстан.

Мәнә шундый тирән мәгънәле, әчтәлекле бәйгедә катнашуыма мин шат. 30 лап конкурсант арасында мин **I урынга** лаек булдым. Җиңүем өчен әтиемә һәм тарихи материал тупларга булышкан өчен тарих укытучыбыз Рафик абыйга рәхмәтле.

***Әминә Туктамышева, X сыйныф укучысы***




## Безнекеләр "Без бергә"дә

Сәнгати-эстетик яктан балаларның һәм яшүсмерләрнең иҗатын үстерү максатыннан 1 нче апрельдә Аксубай районы мәдәният йортында "Без бергә" республикакүләм яшь талантлар фестиваль – конкурсының зона этабы булып узды. Укучыларыбыз бу бәйгедә һәр елны уңышлы чыгыш ясый. Бу юлы сәнгатьле сөйләү номинациясендә **Насыйрова Кәүсәр** I урынны, җыр бәйгесендә I сыйныф укучысы **Закиров Инсаф бабасы Азат абый белән** III урынны, бию конкурсында VI сыйныф укучысы **Нургалиева Ләйлә** III урынны яуладылар. Кул эшләре номинациясендә укучыларыбыз IV сыйныфтан **Закирова Ләйсән** белән VIII сыйныфтан **Нурматова Зәйнәп** I урыннарны алдылар. Мәктәпләр арасындагы күргәзмә бәйгесендә мәктәбебез шулай ук I урынга лаек булды.

Тырыш укучыларга, аларны оештыручы һәм конкурска әзерләүче Рузилә апабызга зур рәхмәтебезне белдерәбез.

***Виктория Нукина, X сыйныф укучысы***

## "Туфан укулары" нәтиҗәләре

Уку елы буена төрле конкурслар читтән торып та уза. Андый бәйгеләргә дә теләп катнашабыз. Узган айда район күләмендә читтән торып уздырылган **"Хәсән Туфан укулары"**ның нәтиҗәләре билгеле булды. Бу бәйгедә катнашкан IV сыйныф укучысы **Насыйрова Кәүсәр – 1 нче**, X сыйныф укучысы **Нукина Вика 3 нче** урыннарны алдылар.

## "Минем яраткан хайваным"

Мәктәбебездә уку белән бергә эстетик тәрбия бирү юнәлеше буенча төрле иҗади конкурслар да үткәрелеп килә. Шул максаттан чыгып, апрель аенда мәктәп күләмендә "Минем яраткан хайваным" исемендәге рәсем конкурсы оештырылды. Нәтиҗәләр буенча I сыйныфтан **Закиров Инсаф**, IV сыйныфтан **Насыйрова Кәүсәр** белән **Закирова Ләйсән**, V сыйныфтан **Хәбибрахманова Хәнифә I урыннарга,** II сыйныфтан **Нурматова Асия** белән VIII сыйныфтан **Нурматова Зәйнәп II урыннарга**, V сыйныфтан Залиева Вәсилә **III урынга** ия булдылар

***Рузилә Хәйруллина, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары***

**/Котлыйбыз!/**



Апрель аенда дөньяга килгән дусларыбыз **Хафизов Ирек** белән **Залиева Вәсиләне** туган көннәре белән котлыйбыз. Укуларында тырышлык, сау-сәламәт булып үсүләрен телибез.

Мәктәпнең завучы **Сафиуллин Илдар абыйны**, химия-биология укытучысы **Туктамышев Рифкать абыйны**, рус теле укытучысы **Кадыйрова Гөлнур апаны**, сабыйларга тәмле ризыклар пешерүче **Йосыпова Айгөл апаны** гомер бәйрәмнәре белән тәбрик итәбез. Сәламәтлек, гаилә иминлеге, эшләрендә зур уңышларга ирешүләрен телибез.